Әлмәт шәһәре Башлыгы
карары

06 апрель 2020 ел № 12

2019 елда Әлмәт муниципаль районы
бюджетының үтәлеше турындагы хисап
буенча гавами тыңлаулар турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы турында» карары белән расланган Әлмәт муниципаль районы Уставының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә гавами тыңлаулар уздыру турында нигезләмә хакында» 2008 елның 31 октябрендәге 63 номерлы карары белән расланган Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә гавами тыңлаулар уздыру турында нигезләмә нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре бюджетының 2019 елда үтәлеше турында хисап буенча 2020 елның 22 апреленә гавами тыңлаулар билгеләргә .
2. Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре бюджетының 2019 елда үтәлеше турында хисап буенча гавами тыңлауларны Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре, Ленин ур., 39 й. (325 нче каб.)адресы буенча Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының зур утырышлар залында 15.15 сәгатьтә уздырырга.
3. Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре бюджетының 2019 елда үтәлеше турында хисап буенча гавами тыңлауларны әзерләү һәм уздыру буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга. (1 нче кушымта)
4. Комиссиягә Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре бюджетының 2019 елда үтәлеше турында хисап буенча фикер алышу үткәрүне һәм кергән тәкъдимнәрне исәпкә алуны йөкләргә.
5. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
6. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л. Ф. Вәлиевка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Әлмәт шәһәре Башлыгының
2020 ел «06» апрель № 12
карары белән расланган
1 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре бюджетының 2019 елда үтәлеше турында хисап буенча гавами тыңлауларны әзерләү һәм уздыру буенча комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| Вәлиев Л.Ф. | - | Комиссия рәисе, Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе; |
| Шәйдуллина З.Р. | - | комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча). |
| Комиссия әгъзалары: | | (килешү буенча) |
| Әхмәтҗанова Л.Р. | - | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе урынбасары; |
| Малышкина Н.Ф. | - | Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының бюджет бүлеге башлыгы; |
| Хәмидуллин Ф.Р. | - | Татарстан Республикасы бюджет-финанс мәсьәләләре буенча Әлмәт шәһәр Советының даими комиссиясе рәисе; |
| Ханнанова Ә.Б. | - | Район Башкарма комитетының Хокук идарәсе начальнигы. |

Аппарат җитәкчесе Р.Е. Әфләтунова